КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 гыйнвар г.Казань № 11

Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 гыйнвар, 11 нче
карары белән расланды

## Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифлары дәүләт тарафыннан җайга салынуга бәйле рәвештә, шулай ук гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрү өчен түләү буенча ташламалар бирүгә бәйле рәвештә, алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен су транспорты оешмаларына (алга таба – сайлап алуда катнашучыларга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү шартларын һәм механизмын билгели.

2. Субсидияләр шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифлары дәүләт тарафыннан җайга салынуга бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсенең су транспорты белән хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның кайбер категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарында күрсәтелгән гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрү өчен түләү буенча ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында бирелә.

3. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен

гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба шул ук эзлеклелектә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Сайлап алуны үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

6. Субсидия алучыны сайлап алу критерийлары:

эчке су транспорты, диңгез транспорты белән пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гамәлдәге лицензия булу;

пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле пассажирлар суднолары Россия Федерациясе законнары нигезендә милек хокукында яисә башка хокукта булу;

агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә халыкка су транспорты белән хезмәте күрсәтүне оештыру өчен Министрлык белән төзелгән шартнамә булу.

7. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

8. Министрлыкның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Субсидия бирү алымы – алынып бетмәгән керемнәрне каплау.

11. Каплау өчен субсидияләр бирелә торган, алынып бетмәгән керемнәр юнәлешләре:

Татарстан Республикасы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча шәһәр яны элемтәләрендә су транспорты белән пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәр;

гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен түләү буенча ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәр.

12. Хисап ае өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = S_{җайга} + S_{ташламалар},$$

монда:

$S_{җайга}$ – шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләгән, җайга салына торган тарифлар кулланылуга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрнең түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләме:

$$S_{җайга} = Р – Д,$$

монда:

Р – Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга чыгымнар;

Д – Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләгән тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырудан алынган керемнәр.

Әгәр $S_{җайга}$ күрсәткече тискәре күрсәткечкә ия булса, исәп-хисапларда нульгә тигез итеп алына;

$S_{ташламалар}$ – Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән гражданнарның кайбер категорияләрен йөртүдән алынып бетмәгән керемнәр күләме; субсидия алучы хисап аенда, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тарифлар буенча юл йөрү документлары (билетлар) рәсмиләштерелгән очракта, әлеге пассажирларны йөртүдән ала алган керемнәр һәм субсидия алучының Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге тарифлар буенча 50 процентлы ташлама рәвешендә ташламалар, шулай ук шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән гражданнарның кайбер категорияләренә хезмәтләр күрсәтү өчен юл йөрү документын (билет) сатып алганда түләүсез юл йөрү хокукы билгеләнүгә бәйле рәвештә алынган керемнәре арасындагы аерма буларак билгеләнә.

13. Агымдагы финанс елының декабре өчен бирелә торган субсидия күләме әлеге Тәртипнең 49 пункты нигезендә бирелгән фараз хисаплары буенча субсидия алучының фараз күрсәткечләре күләмендә билгеләнә.

Әгәр агымдагы финанс елының декабре өчен бирелгән субсидия күләме әлеге Тәртипнең 48 пунктында күрсәтелгән, субсидияләр алучы тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә әлеге чор өчен субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләменнән артып киткән булса, артып киткән сумма чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр агымдагы финанс елының декабре өчен бирелгән субсидия күләме әлеге Тәртипнең 48 пунктында күрсәтелгән, субсидияләр алучы тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә әлеге чор өчен субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләменнән азрак булса, җитеп бетмәгән сумма әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган субсидия алучыга, кабат сайлап алу аша узмыйча, чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр күчерелә.

14. Бирелә торган субсидия күләмен исәпләү өчен күрсәткечләр субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 48 һәм 49 пунктларында билгеләнгән документларда күрсәтелә.

15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәсе кулланыла: агымдагы финанс елның 31 декабренә карата агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру шартнамәсе нигезендә су транспорты хәрәкәте параметрлары белән каралган гомуми күләмнән агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кимендә 90 процент даими рейслар башкару.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең тасвирнамәләре:

а) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территорияләрендә су транспорты белән шәһәр янында су транспорты белән йөртүләрне колачлау;

б) агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру шартнамәсендә каралган, Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртелгән маршрутлар саны.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

16. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы (алга таба – БМО) уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмау;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

17. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта, Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел (сайлап алуда катнашучы әлеге документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

### III. Сайлап алуны уздыру турында белдерүне формалаштыру һәм урнаштыру тәртибе

18. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлык тарафыннан, «Электрон бюджет» системасында Министрлык белдерүне формалаштырган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, бердәм порталда субсидия турында мәгълүмат басылып чыкканнан соң урнаштырыла.

19. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

заявкаларны карау кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү

нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге пунктында билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 3 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

20. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Министрлык тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

21. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы – әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә Министрлыкка кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире алу.

22. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрмәү турында мәгълүмат «Электрон бюджет» системасында бирелә.

23. Сайлап алу бердәм порталда аны уздырмау турында белдерү урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

24. Әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Министрлык Россия Федерациясе Граждан кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны үткәрелмәскә мөмкин.

V. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан
заявкаларны булдыру һәм бирү тәртибе

25. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявкаларны «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштыра һәм тапшыра, документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасына күчереп кертә:

эчке су транспорты, диңгез транспорты белән пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гамәлдәге лицензия;

Россия Федерациясе законнары нигезендә милек хокукында яисә башка хокукта булган пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле пассажирлар суднолары булуныраслый торган документлар;

заявка биргәнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан алынган сайлап алуда катнашучы турында белешмәләр.

26. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

27. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

28. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә сакланган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелә торган фото һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

29. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы булып заявкага “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

30. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

салым органында исәпкә куелу датасы һәм коды

юридик затның адресы;

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителә торган субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече, сорала торган субсидия күләме.

31. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

32. Теләсә кайсы сайлап алуда катнашучы бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән, заявкалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында их күбе ике рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

33. Министрлык әлеге Тәртипнең 32 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VI. Заявкаларны карау, шулай ук сайлап алуда җиңүчене билгеләү тәртибе

34. Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга Министрлык керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Министрлыкка «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелгән заявкаларга керү мөмкинлеге бирелә.

35. Министрлык сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик затның адресы.

36. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

37. Әгәр заявка сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әгәр заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, ул дөрес дип таныла.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

38. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

а) сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

б) сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

в) тапшырылган документларның һәм (яисә) заявкаларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

г) заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

д) гаризалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң гариза бирү.

39. Сайлап алу түбәндәге очракларда булмаган дип таныла:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

40. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

41. Әлеге Тәртипнең 6 һәм 16 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче булып карап тикшерүгә тапшырылган сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче дип танныла.

42. Сайлап алуны төгәлләү һәм анда җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куелган көннән соң килә торган икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

## VII. Килешүләр төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

43. Министрлык тарафыннан сайлап алу нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

44. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

45. Министрлык сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

46. Әгәр Министрлык әлеге Тәртипнең 45 пунктында каралган нигезләр буенча сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тартса, җиңүче килешү төзүдән баш тартса, сайлап алуда җиңүче сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән срок эчендә килешүгә кул куймаса, Министрлык килешү төзү турындагы тәкъдимне, әлеге Тәртиптә билгеләнгән критерийларга, таләпләргә һәм шартларга туры килә торган, заявкалар рейтингында заявкасы киму тәртибендә җиңүче дип танылган соңгы җиңүчедән соң килә торган башка катнашучыга җибәрә.

47. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

48. Хисап аена субсидия алу өчен субсидия алучы Министрлыкка ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15нче көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәге документларны тапшыра:

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырудан башкарылган чыгымнар һәм алынган керемнәр турында һәм дәүләт тарафыннан тарифлар җайга салынуга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәр күләмнәре (субсидия алучы эшенең техник-икътисадый күрсәткечләре);

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрүгә түләү өчен ташламалар бирү турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән гражданнарның кайбер категорияләрен йөртүдән алынып бетмәгән керемнәре турында хисап.

49. Агымдагы финанс елының декабрь аена субсидия алу өчен субсидия алучы Министрлыкка агымдагы финанс елның 25 декабренә кадәр түбәндәге документларны тапшыра:

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырудан планлаштырыла торган чыгымнар һәм керемнәр турында һәм дәүләт тарафыннан тарифлар җайга салынуга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрнең планлаштырыла торган күләмнәре (субсидия алучы эшенең техник-икътисадый күрсәткечләре) турында фараз хисап;

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрүгә түләү өчен планлаштырыла торган ташламалар бирү турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән гражданнарның кайбер категорияләрен йөртүдән алынып бетмәгән керемнәре турында фараз хисап.

50. Әлеге Тәртипнең 48, 49 пунктларында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча бирелергә тиеш.

51. Министрлык:

әлеге Тәртипнең 48, 49 пунктларында күрсәтелгән документларны алар кергән көнне терки;

документлар теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

52. Хисап ае өчен субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

әлеге Тәртипнең 48 һәм 49 пунктларында билгеләнгән документларда субсидия алучы тарафыннан күрсәтелгән, тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

53. Министрлык субсидия алучыга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына күчерә.

## VIII. Хисаплар бирү, субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җавап бирү тәртибе

54. Субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүләр өчен билгеләнгән бертип форма буенча квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның соңгы көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында субсидия бирү нәтиҗәсе һәм тасвирнамә күрсәткеченә ирешү турында хисап, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 гыйнварыннан соңга калмыйча, еллык хисап тапшыра.

55. Министрлык әлеге хисап тапшырылган көннән алып 15 эш көненнән артмаган срок эчендә субсидия бирү нәтиҗәсе һәм тасирнамәләр күрсәткеченә ирешү турында хисап тикшерүне гамәлгә ашыра.

56. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

57. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

58. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча да – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсе һәм тасвирнамәләр күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшырылмаган очракта – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсе һәм тасвирнамәләр күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта – субсидияләр бирү нәтиҗәсенең һәм тасвирнамәләрнең ирешелмәгән күрсәткечләренең чагыштырма авырлыгыннан чыгып билгеләнә торган күләмдә.

59. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 58 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогын бозылган очракта, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү буенча чаралар күрә.